КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 сентябрь г.Казань № 1114

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләре буенча агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләре буенча агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021ел, 3 июль, 534 нче; 2021 ел, 20 август, 750 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 951 нче; 2021 ел, 17 декабрь, 1245 нче; 2022 ел, 15 март, 239 нчы; 2022 ел, 13 июль, 673 нче, 2022 ел, 27 сентябрь, 1038 нче, 2023 ел, 11 февраль, 133 нче, 2023 ел, 22 июнь, 734 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «мелиоратив эшләр» сүзләрен «мелиоратив чаралар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 15 пунктының бишенче абзацына «1 тонна өчен» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Мелиорация эшләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «мелиоратив эшләр» сүзләрен «мелиоратив чаралар» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның беренче абзацында «мелиоратив эшләр» сүзләрен «мелиоратив чаралар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин